РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

---

Постановление Карар

2021 елның 5 апреле Чистай шәһәре № 18

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «2020 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьясы, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Ачык тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 18 июлендәге 35/5 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «2020 елгы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыруны 2021 елның 20 апреленә 11-00 сәгатькә Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты конференц-залында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Чистай шәһәре, Бебель ур., 129 нчы йорт.

2. Фикер алыша торган проект буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча язма рәвештә җибәрелә: Чистай шәһәре, Бебель ур., 129 нчы йорт, 19 нчы каб., 5-43-70 факсы буенча яки chistay@tatar.ru электрон почта адресы буенча, ачык тыңлаулар үткәрү көненә кадәр. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 гә кадәр (төшке аш 12-00 дән 13-00 сәгатькә кадәр) кабул ителә.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «2020 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты үтәлеше турында» (алга таба - оештыру комитеты)

түбәндәге составта карары проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә:

Иванов К.В.- Чистай муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары;

Карманова Н.А. - Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе;

Хаматов Р.Г. - Чистай авыл җирлегеннән депутат, Чистай муниципаль районы Советының Бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясе рәисе;

Осипов Г.Н. - Түбән Кондрата авыл җирлегеннән депутат, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясе рәисе;

Садриева И.Ш. - Чистай муниципаль районы Советы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итү бүлеге начальнигы;

Абзалова Л.Н. - Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлеге начальнигы;

Гәрәев Н.В. - «Водников поселогы» 7 нче ТОС җитәкчесе (килешү буенча).

4. Тапшырырга:

- оештыру комитетына ачык тыңлаулар үткәрүне, күрсәтелгән карар проекты буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә;

- Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының бюджет һәм фаразлау буенча даими депутат комиссиясенә, ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы утырышына проектны кертергә.

5. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «2020 елга Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджеты үтәлеше турында» карары проектын билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтына урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башлыгының беренче урынбасары К.В. Ивановка йөкләргә.

Чистай муниципаль районы башлыгы
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы К.В. Иванов